СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№2-35 от 15 апреля 2024 г

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчыавыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 2 мартындагы N 25-ФЗ федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-8 карары (алга таба- Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт өстәргә:

« 3) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең (алга таба – анкетадагы белешмәләр) аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле(эш бирүче) карары буенча үзгәргән белешмәләрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә.»

7.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә урнашканда һәм (яисә) аны узу чорында чикләәрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне

үтәүне раслаучы ялган документлар һәм (яисә) белә торып ялган белешмәләр тапшырса яисә чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне , тыюларны һәм тәләпләрне үтәмәүне дәлилли торган документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшырмаса;»

1.3. 24.2 пунктта:

1) 11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт өстәргә:

"11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;".

1.4. 12.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

1.5. 12.4 пунктта «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетада күрсәтелгән белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.6.түбәндәге эчтәлекле 11.2 бүлек өстәргә:

«11_2. Анкета тапшыру, анкетада булган белешмәләрнең үзгәүе турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү

1. Граждан муниципаль хезмәткә урнашканда анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетадагы белешмәләрдәге аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкетаның формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4.Анкетадагы белешмәләр яллаучы вәкиленең ( эш бирүченең) яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарарфыннан тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органннарына һәм оешмаларга язмача соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органннары һәм оешмалар соратыла торган мәгълүматны әлеге соратуны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге башлыгы А.Я.Ильинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Мамадыш муниципаль районы<br>
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,<br>
авыл җирлеге Советы рәисе /А.Я.Ильин/